СОВЕТ ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“13” апрель 2021 ел — № 3-7

## Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль Закон, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышының гомуми принципларын раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 885 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы Президиумының 2010 елның 23 декабрендәге 21 номерлы утырышы беркетмәсе нигезендә, муниципаль хезмәткәрләрнең этик нормаларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү максатларында Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының 2011 ел 19апрель, № 4-6 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына (алга таба – Кодекс) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителгән нормаларны һәм таләпләрне үтәү турында мәгълүматны эшкәртә һәм тапшыра.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми http://mamadysh.tatarstan.ru/ сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгы Л.Н.Хәбибуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Л.Н.Хәбибуллин/

СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ